Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның 26 декабрендәге № 126

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында«2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставы , гавами тыңлауларның 2022 елның 19 декабрендәге беркетмәләре нигезендә , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы тарафыннан үткәрелгән һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегенең Генераль планын кушымта нигезендә электрон чыганакта расларга.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru/).

3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегенең генераль планын раслау турында элек кабул ителгән карарның үз көчләрен югалткан дип танырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль район Советы рәисе Н. А. Вазыйхов